

# Динебез турында уй — хисләрем

Кадерле милләттәшләрем! Дин кардәшләрем!

Менә "Туган як" гәҗитенең 2нче санын укып, күңелем хушланды. Бигрәк тә Фәрит әфәнде Нугумановның хаж сәфәре турында язган язмасын укыгач, бик шатландым. Без бит бер төркемдә идек, мин дә барган идем былтыр. Тагын анда йөргән бәхетле мизгелләр искә төште...

Дин кардәшләрем белән динебез турындагы уй-хисләрем белән уртаклашмакчы булдым. Ниятем: динебез турында әз булса да кирәкле мәгълүмат бирергә тырышу. Мөселман кешесенең җан азыгы — ул дини белем алу. Рәсүлебез с.г.в. безгә бишектән алып ләхеткә чаклы белем алырга кушкан. Бүгенге мөселманнарның күпчелеге дини мәгълүмат алуга мохтаҗ. Дини вәгазь — нәсыйхәт ул җан азыгы. Аның аркылы кешенең иманы ныгый, үсә.

Ничек сукыр кеше таягы белән капшап юл эзләгән кебек, без дә, хәзерге мөселманнар, һәрбер дин турында әйтелгән сүзгә ышанып, гореф — гадәтләребезне дә дин дип белеп, чын исламнан бик ерак торган хәлебездә дә, үзебезне юк — бар белән юатып, тиешенче Аллаһудан курка да белмәгән хәлебездә, "Аллаһ рәхимле, кичерер әле", дип, гомер уздырып, гафләт йокысында кала бирәбез. Шуңа күрә мин, әз булса да, кардәшләрем иманы артса, миңа да савап булыр дип, язып утырам.

Без, хатын — кызлар, Богырысланда мәчеттә укыйбыз, инде 3-4 ел буладыр. 20-30 хатын Корьәнне үзе карап, тәҗвид белән укый ала. Алар бик куаналар, мәгънәсен дә белик дип, гарәп телен өйрәнәләр. Ә Корьәндә шундый аятьләр бар, матурлыгына, дөреслегенә ис китеп, шатлыктан елыйсы килә. Мине куандырган шундый аятьләрнең берсе:

"Иннә әкрамәкүм гиное — Ллаһи эткакум". Мәгънәсе: Аллаһу Тәгалә бу дөньяда кем булуыңа карамый, ахирәттә иң хөрмәтле кеше, Аңа буйсынып яшәүче кеше була.(ягъни бу дөньяда син бай булмасаң да, этеп — төртеп йөртсәләр дә, Ахирәттә, Аллаһ кушканча яшәгән булсаң, үзеңә тиешле хөрмәтне алачаксың, диелә. Иншә, Аллаһ.)

Дөнья җиңел түгел, гаделлек табу да кыен. Шушындый аятьләрне укыгач, ничек шатланмыйсың, ничек: "Әй, Раббым! Ярый әле син бар", — димисең.

Күңел йомшарып, Аллаһудан яхшылык сорарга уйлаганда, үз ана телебездә сорарга да ярый. Бер — ике дога рәвешен китереп китәм:

1.И, Раббым! Гафу ителмәгән гөнаһларымны калдырма, җан тынычсызлыгыннан, хәсрәттән коткар! Син риза булырлык бер генә догамны, соравымны да җавапсыз калдырма!

2.И, Аллаһым! Синнән Үзеңнең рәхмәтеңә мине якынайтуыңны сорыйм, мине

Үзеңнең ярлыкавыңа илтә торган юлга сал!

Барыбызга да Аллаһудан хәерле гомер, тулы иман сорап калучы Гәлимә апагыз.

**Гәлимә Хакимова,**
**мөгаллимә, хаҗия.**
**Богырыслан шәһәре.**

ЭТО ИНТЕРЕСНО

# Әйтемнәр һәм фразалар

Авыз ачу. (уразада кич ашау)

**Авызда ботка пешерү. (сүзен рәтле сөйли алмау)**

Авыздан сулар килү. (тәмле әйбергә кызыгып)

**Авыз күтәреп калу. (өлештән калу)**

Авыз пешкән. (алданылган)

**Авыз суын корыту. (гел сөйләү)**

Авыз тутырып әйтү. (кыенсынмыйча, тарсынмыйча)

**Авыз чайкау. (яманат сөйләү)**

Авызын ачса үпкәсе күренә. (бик ярлы һәм ябык)

**Авызында ашы — күзендә яше. (рәхәттә яшәп зарланучы тур.)**

Авызына шайтан төкергән. (җор сүзле кеше тур.)

**Авызы колагына җиткән. (бик шат)**

"Авызы ни сөйләгәнне колагы ишетми".

**Авызын каплау (томалау, ябу). (оста җавап кайтару)**

"Авызыңа бал да май!" (яхшы хәбәр әйтүчегә яки яхшыга юраучыга җавап)

**Авызыңнан кереп артыңнан чыга. (бик юмакай кеше)**

"Авызыңнан җил алсын". (бүтәнчә телгә алмаска)

**"Авызыңны үлчәп ач".**

Авыртмас башка тимер таяк. (өстәмә бәлә)

**"Агай — олы, мин — зур".**




# Кипкән җимешләр белән дөге бәлеше

Мондый бәлеш төче кмырдан пешерелә. Камырны җәеп майлаган табага салырга. Җәем табаның кырыйларын каплап торырга тиеш. Алдан бүрттерелеп суытылган дөгене камыр өстенә тигез итеп салырга, күп итәп сары май яки эреткән атланмай салырга һәм парда йомшарткан йөзем җимешне, төше алынган өрек яки кара җимеш тезәргә дә тагын бер катлам дөге җәяргә. Аннан юка итеп җәйгән камыр белән капларга, кырыйларын чеметеп ябыштырып чыгарга да мичкә яисә духовкага куярга. Бәлеш эченә шикәр комы да салырга мөмкин. Юка бәлеш 40-50 минут пешә. Әзер бәлешне өлешләргә кисеп табынга кайнар килеш бирергә. Аерым савытта эреткән атланмай куела.

**(Бер бәлешкә: 1,2 кг. Төче камыр, 400 г.дөге, 400-500 г.җиләк-җимеш, 200-300 г. май, 200 г. шикәр комы).**

# Чия бәлеше

Әзер әче камырны ике тигез булмаган кисәккә бүләргә.Зуррак кисәген 0,5 см калынлыкта җәеп табага салырга һәм төшен алган, юган чияне тезәргә дә өстенә шикәр комы сибәргә. Камырның калганын җәеп чия өстенә капларга һәм бәлешнең кырыйларын ябыштырып мичкә тыгарга. Чия бәлешнен кабартып тормыйлар, чөнки чия суы чыгып камырны җебетүе ихтимал.

**(Бер бәлешкә: 1кг камыр; 600-800 г. чия, 250 г. шикәр комы, 1 йомырка (бәлеш өстенә сөртү өчен)).**

# НАМАЗ ВАКЫТЛАРЫ



(время местное)

| Март | Фаджр Иртә | Восход Кояш чыга | Зухр Өйлә | Аср Икенде | Магриб Ахшам | Иша Ясту |
|---|---|---|---|---|---|---|
| 1 | 7-20 | 8-20 | 14-10 | 17-12 | 19-12 | 20-42 |
| 2 | 7-17 | 8-17 | 14-10 | 17-13 | 19-13 | 20-43 |
| 3 | 7-15 | 8-15 | 14-10 | 17-15 | 19-15 | 20-45 |
| 4 | 7-12 | 8-12 | 14-10 | 17-17 | 19-17 | 20-47 |
| 5 | 7-10 | 8-10 | 14-10 | 17-19 | 19-19 | 20-49 |
| 6 | 7-08 | 8-08 | 14-10 | 17-21 | 19-21 | 20-51 |
| 7 | 7-05 | 8-05 | 14-10 | 17-23 | 19-23 | 20-53 |
| 8 | 7-03 | 8-03 | 14-10 | 17-25 | 19-25 | 20-55 |
| 9 | 7-01 | 8-01 | 14-10 | 17-27 | 19-27 | 20-57 |
| 10 | 6-58 | 7-58 | 14-10 | 17-29 | 19-29 | 20-59 |
| 11 | 6-55 | 7-55 | 14-10 | 17-31 | 19-31 | 21-01 |
| 12 | 6-53 | 7-53 | 14-10 | 17-32 | 19-32 | 21-02 |
| 13 | 6-51 | 7-51 | 14-10 | 17-34 | 19-34 | 21-04 |
| 14 | 6-49 | 7-49 | 14-10 | 17-36 | 19-36 | 21-06 |
| 15 | 6-47 | 7-47 | 14-10 | 17-38 | 19-38 | 21-08 |
| 16 | 6-44 | 7-44 | 14-10 | 17-40 | 19-40 | 21-10 |
| 17 | 6-41 | 7-41 | 14-10 | 17-42 | 19-42 | 21-12 |
| 18 | 6-39 | 7-39 | 14-10 | 17-43 | 19-43 | 21-13 |
| 19 | 6-37 | 7-37 | 14-10 | 17-45 | 19-45 | 21-15 |
| 20 | 6-35 | 7-35 | 14-10 | 17-47 | 19-47 | 21-17 |
| 21 | 6-32 | 7-32 | 14-10 | 17-49 | 19-49 | 21-19 |
| 22 | 6-29 | 7-29 | 14-10 | 17-51 | 19-51 | 21-21 |
| 23 | 6-27 | 7-27 | 14-10 | 17-53 | 19-53 | 21-23 |
| 24 | 6-25 | 7-25 | 14-10 | 17-55 | 19-55 | 21-25 |
| 25 | 6-23 | 7-23 | 14-10 | 17-57 | 19-57 | 21-27 |
| 26 | 6-20 | 7-20 | 14-10 | 17-59 | 19-59 | 21-29 |
| 27 | 6-17 | 7-17 | 14-10 | 18-01 | 20-01 | 21-31 |
| 28 | 6-15 | 7-15 | 14-10 | 18-03 | 20-03 | 21-33 |
| 29 | 6-12 | 7-12 | 14-10 | 18-05 | 20-05 | 21-35 |
| 30 | 6-10 | 7-10 | 14-10 | 18-07 | 20-07 | 21-37 |
| 31 | 6-07 | 7-07 | 14-10 | 18-08 | 20-08 | 21-38 |

**Данные предоставлены Бугурусланским муфтиятом.**
**Возможна разница во времени в сравнении с другими источниками, на 3-5 минут.**

ТУГАН ЯК
РОДНОЙ КРАЙ
E-MAIL: tugan-iak-asekeevo@yandex.ru

**УЧРЕДИТЕЛЬ:**
ТАТАРСКАЯ НАЦИОНАЛЬНО КУЛЬТУРНАЯ АВТОНОМИЯ
**АДРЕС РЕДАКЦИИ:**
С.АСЕКЕЕВО, УЛ.ЧАПАЕВА 24.
**ТЕЛЕФОН:** (353-51) 2-22-81

Распространяется в Асекеевском, Абдулинском, Бугурусланском, Матвеевском, Пономаревском районах.
Свидетельство о регистрации ПИ №ТУ 56-00065, выданное Управлением Федеральной службы по надзору в сфере связи и массовых коммуникаций по Оренбургской области.

Газета отпечатана в Бугурусланской типографии. 461600, г. Бугуруслан, ул. Революционная, 14.
Цена свободная. ТИРАЖ: 2000 ЭКЗ.

**Главный редактор: Фарит НУГУМАНОВ**